**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**АЛЬКЕЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422870, С.Базарные Матаки,
ул.С.Крайнова,д.56

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘЛКИ**
**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422870, РТ Базарлы Матак авылы,
С.Крайнов ур.,56

Телефон: (84346) 20-0-26, факс: (84346) 21-7-60. E-mail: alkay@tatar.ru, сайт: www.alkeevskiy.tatarstan.ru.

---

2014 елның 22 апреле 159№

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының
2013 елның 20 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү
программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына
йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм
чаралары күрсәтү турында» 419 номерлы карарына
үзгәрешләр кертү хакында

Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты түбәндәгеләрне КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 20 сентябрендәге «Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 419 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

Тәртипнең 1.6 пунктында (компенсацияне исәпләү формуласында) абзац:

«Ф -мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен фактта балага кертелгән түләүнең күләме;» түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Ф - мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмасында баланы карау һәм тәрбияләү өчен фактта түләнә торган ата-аналар түләве күләме башкарма комитет карары белән расланган;».

2. Карарны түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга: «Белем бирү программасын яңа срокка гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларга өстәмә компенсация алу хокукын яңадан рәсмиләштерү 2014 елның 3 аенда (июль, август, сентябрь) мөрәҗәгать иткән айга кадәр өстәмә компенсация түләүне туктатып тормыйча график буенча гамәлгә ашырыла.»

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль
районы Башкарма комитет җитәкчесе: А.Ф. Никошин